Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданка Р.М. Рисухина шикаятенә бәйле рәвештә «Муниципаль милектәге мөлкәтне бүлешүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» 2008 елның 6 августындагы 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2019 елның 5 марты

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Муниципаль милектәге мөлкәтне бүлешүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» 2008 елның 6 августындагы 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка Р.М. Рисухина шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив

нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Ф.Р. Волкова мәгълүматын, яклар — гражданка Р.М. Рисухина, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең граждан законнары бүлеге мөдире И.И. Фәттахов, суд утырышына Татарстан Республикасы Конституция суды инициативасы буенча чакырылган белгечләр — Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы З.Д. Каюмова, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты юридик бүлеге башлыгы урынбасары Р.Н. Сафин аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге баш киңәшчесе Р.В. Сидаков, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтле вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Э.С. Каминский, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге баш белгече Э.И. Гафиятуллина, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы А.Г. Бартенев

чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Р.М. Рисухина «Муниципаль милектәге мөлкәтне бүлешүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» 2008 елның 6 августындагы 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Законы муниципаль мөлкәтне бүлешүгә инициатива белдерү механизмын, шулай ук бүленергә тиешле муниципаль мөлкәт исемлекләрен килештерү тәртибен кертеп, җирле үзидарә органнары арасында муниципаль мөлкәтне бүлешүгә бәйле мөнәсәбәтләрне һәм башка мәсьәләләрне җайга сала.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән, гражданка Р.М. Рисухинаның Татарстан Республикасы Конституция суды утырышындагы чыгышыннан аңлашылганча, ул Казан шәһәрендә элегрәк Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Кавал авыл җирлеге территориясенә караган «Татваленка» ярдәмче хуҗалыгының Озерная урамындагы торак йортта теркәлгән һәм гаиләсе белән яши. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртеп кору, үзгәртү һәм Татарстан Республикасының кайбер законнарына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 28 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Казан шәһәре һәм Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләре үзгәртелгән, шуның нәтиҗәсендә «Татваленка» ярдәмче хуҗалыгы территориясе Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләренә кертелгән.

Мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәрткәннән соң һәм хәзерге вакытка кадәр торак фонды, шул исәптән

гаиләсе белән яши торган торак йорт та Татарстан Республикасы Законы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге милкенә тапшырылмаган дип раслый. Барлыкка килгән хәлне чишү өчен гражданка Р.М. Рисухина Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясенә аны һәм аның гаиләсе әгъзаларын торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую турында гариза белән мөрәҗәгать иткән, әмма аларга бу торак урын Казан шәһәренең муниципаль милкендә булмавы нигезендә баш тартылган. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Кавал авыл җирлеге Башкарма комитеты аның гаризасына җавап биреп, алар йортының билгеләнгән тәртиптә Казан шәһәренең муниципаль мөлкәте составына күчүе турында хәбәр иткән. Гражданка Р.М. Рисухина прокуратура органнарына да, дәүләт хакимиятенең башка органнарына да мөрәҗәгать иткән, бу исә аның мәсьәләсен хәл итүгә шулай ук китермәгән. Нәтиҗәдә, мөрәҗәгать итүче билгеләп үткәнчә, озак вакыт дәвамында аның һәм аның гаиләсе әгъзаларының социаль торак алуга, яшәү урыны буенча теркәлүгә конституциячел хокуклары, сайлау һәм башка хокуклары бозыла. Мөрәҗәгать итүче теркәлгән йорт, аның фикеренчә, авария хәлендә, коммуникацияләр бөтенләй юк, шуңа күрә ул гаиләсе белән башка торак япларга мәҗбүр.

Гражданка Р.М. Рисухина үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләренең бозылуын шунда күрә: дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән муниципаль мөлкәтне бүлешүгә инициатива белдерү механизмын (2 статья) һәм бүленергә тиешле муниципаль мөлкәт исемлекләрен килештерү тәртибен (3 статья), шулай ук муниципаль мөлкәтне бүлешкәндә каршылыкларны җайга салуны (5 статья) регламентлаштыра торган хокукый җайга салу муниципаль мөлкәтне бер муниципаль берәмлек милкеннән башка муниципаль берәмлек милкенә аларның чикләрен үзгәрткән очракта тапшырмаска мөмкинлек бирә. Мөрәҗәгать итүче китерелгән закон нигезләмәләре аларның системалы

берлегендә күрсәтелгән очракта җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль мөлкәтне бүлешүгә бөтенләй инициатива белдермәскә, ә мөлкәт исемлекләрен килештергәндә каршылыклар барлыкка килгәндә — аларны җайга салу өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр органына мөрәҗәгать итмәү мөмкинлегенә юл куялар дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Р.М. Рисухина Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Муниципаль милектәге мөлкәтне бүлешүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законын Татарстан Республикасы Конституциясенең 18 (беренче өлеш), 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 55 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә Татарстан Республикасында хосусый, дәүләти, муниципаль милек һәм милекнең башка рәвешләре бертигез дәрәҗәдә танылa һәм яклана; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазифаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше я аларга өстенлекләр билгеләү тыела; һәркем торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның

мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Әлеге эш буенча карау предметын билгеләгәндә, Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгать итүченең, карала торган Татарстан Республикасы Законының конституциячеллегенә тулысынча дәгъва белдереп, фактта, аның шикаяте эчтәлегеннән һәм Татарстан Республикасы Конституция суды утырышындагы чыгышыннан күренгәнчә, аның аерым нигезләмәләренә, атап әйткәндә, 2 статьясындагы 1 өлешенә, 3 статьясына һәм 5 статьясындагы 1 өлешенә шикаять белдерүен исәпкә ала.

Шулай итеп, «Муниципаль милектәге мөлкәтне бүлешүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» 2008 елның 6 августындагы 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлеше, 3 статьясы һәм 5 статьясындагы 1 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләре аларга хокук куллану практикасында бирелә торган мәгънә буенча Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлеше һәм 3 статьясы муниципаль берәмлекләр чикләрен үзгәрткәндә муниципаль мөлкәтне муниципаль берәмлекләр арасында бүлешкәндә аны тапшыру (кабул итеп алу) инициативасын белдермәскә рөхсәт иткән, ә 5 статьясындагы 1 өлеше муниципаль мөлкәтне бүлешкәндә каршылыкларны җайга салу тәртибен билгеләп, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр органына (алга таба — башкарма хакимият органы) якларның берсе муниципаль мөлкәтне тапшыру (кабул итеп алу) инициативасын белдергән булып, икенче як килгән тәкъдимне карамаган очракта җирле үзидарәнең вәкаләтле органы мөрәҗәгать итү мөмкинлеген күздә тотмаган

дәрәҗәдә әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар.

2. Муниципаль мөлкәтне бүлешү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының дәгъвалана торган закон акты җирле үзидарәне оештыру өлкәсенә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясындагы 1 өлешенең «н» пункты нигезендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары системасын оештыруның гомуми принципларын билгеләү Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагына керә. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясындагы 2 һәм 5 өлешләре буенча Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла, алар Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләр буенча, шулай ук Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча кабул ителгән федераль законнарга каршы килә алмый.

Төрле дәрәҗәдәге муниципаль берәмлекләр арасында муниципаль мөлкәтне бүлешү мәсьәләләре «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларын үз көчен югалткан дип тану турында» 2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба шулай ук — 122-ФЗ номерлы Федераль закон ) белән җайга салына.

Күрсәтелгән Федераль законның 154 статьясындагы 11.1 өлеше муниципаль милектәге мөлкәтне муниципаль берәмлекләр арасында бүлешкәндә аны түләүсез тапшыру тәртибен, шул исәптән мондый бүлешүне

гамәлгә ашыру тәртибен, мөлкәткә милек хокукы турында бәхәсләрне хәл итү тәртибен, җирле үзидарә органнары тарафыннан мөлкәтне тапшыру (кабул итеп алу) срокларын, тапшырыла торган мөлкәт исемлекләрен раслау тәртибен һ.б. билгели. Шул ук вакытта аталган Федераль законның 154 статьясындагы 11.1 өлешенең 13 абзацында тапшырылырга тиешле мөлкәт исемлеген килештерү тәртибе, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тиешле муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан килештерелгән тәкъдимнәр җибәрү тәртибе һәм мөлкәтне бүлешү турында Россия Федерациясе субъектының хокукый актын кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә дип каралган.

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган Законны кабул итеп, республика закон чыгаручысы федераль законнар нигезендә үзенә бирелгән, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы (2 пункт) нигезләмәләренә таянган вәкаләтләрне законлы рәвештә гамәлгә ашырган, алар нигезендә Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләрне Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә закон чыгарып җайга салу Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасының конституциячел корылышы нигезләрен беркетеп, Татарстан Республикасы Конституциясе үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль булган җирле үзидарәне таный һәм гарантияли (10 статья). Татарстан Республикасы Конституциясенең 3 (беренче һәм икенче өлешләр), 13, 45 (беренче һәм икенче өлешләр), 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьялары белән системалы берлектәге әлеге нигезләмә мәгънәсе буенча кешенең лаеклы тормышы һәм ирекле үсеше өчен шартлар тудыру буенча дәүләт бурычларын гамәлгә ашыруда катнашып, җирле үзидарә халык хакимияте бердәм механизмының состав өлеше булып һәм халыкның, үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итүен,

муниципаль милек биләүне, аннан файдалануны һәм аның белән эш итүне тәэмин итә торган үзоешу рәвеше булып тора.

Тиңдәш җайга салу Россия Федерациясе Конституциясенең 3 (3 өлеш), 7 (1 өлеш), 12, 32 (1 һәм 2 өлешләр), 130 (1 өлеш) һәм 132 (1 өлеш) статьяларында беркетелгән.

Әлеге конституциячел нигезләмәләр 1985 елның 15 октябрендәге Европа җирле үзидарә хартиясе нормаларына туры килә, Россия Федерациясе өчен ул 1998 елның 1 сентябреннән үз көченә керә. Анда җирле үзидарә принцибы эчке законнарда танылырга тиеш; җирле үзидарә дигәндә җирле үзидарә органнарының закон кысаларында, җаваплылык тоеп һәм җирле халык мәнфәгатьләрендә эш итеп, гавами эшләрнең күп өлешен җайга салу һәм алар белән идарә итү хокукы һәм реаль сәләте аңлашыла дип билгеләнгән (2 статья; 3 статьяның 1 өлеше).

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, җирле үзидарә органнарының конкрет муниципаль берәмлектәге халыкның көнкүрешен тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча аның конституциячел табигатенә бәйле бурычларны тиешенчә үтәве муниципаль гавами хакимият оештыру өлкәсендә демократик хокукый дәүләтнең императивы булып тора; бу максатларда Россия Федерациясе Конституциясе җирле үзидарә органнарына муниципаль милек белән мөстәкыйль идарә итү вәкаләтләре бирә; җирле үзидарәнең мөстәкыйльлеген аның төп сыйфаты һәм дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләр принцибы буларак беркетеп, Россия Федерациясе Конституциясе шул ук вакытта әлеге мөстәкыйльлекнең абсолют булмавына, ә гамәлдәге законнар белән билгеләнгән чикләрдән чыгып билгеләнергә тиешлегенә таяна (2002 елның 2 апрелендәге 7-П номерлы, 2011 елның 29 мартындагы 2-П номерлы, 2011 елның 18 маендагы 9-П номерлы, 2012 елның 30 мартындагы 9-П номерлы, 2013 елның 27 июнендәге 15-П номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге 26-П номерлы карарлар).

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми хокукый, территориаль, оештыру һәм икътисади принциплары «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба шулай ук — 131-ФЗ номерлы Федераль закон) белән билгеләнгән, аның 50 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты һәм 5 өлеше нигезендә муниципаль берәмлекләр милкендә әлеге Федераль законда билгеләнгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен каралган мөлкәт булырга мөмкин.

Бер муниципаль берәмлекнең аерым торак пунктлары территорияләрен икенче муниципаль берәмлек территориясенә кертүне китереп чыгара торган муниципаль берәмлекләр чикләрен үзгәртү очрагында муниципаль мөлкәт 122-ФЗ номерлы Федераль законның 154 статьясындагы 11.1 өлеше нигезләмәләре белән каралган тәртиптә бүленергә тиеш. Шул ук вакытта мондый бүлешүне закон белән регламентлаштыру буенча тиешле вәкаләтләр Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән.

Республика закон чыгаручысы федераль законнар таләпләрен үтәүне тәэмин итү максатларында, үз вәкаләтләре чикләрендә эш итеп, муниципаль мөлкәтне бүлешү мәсьәләләрен дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законында җайга салган.

Шулай, дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлеше белән шул билгеләнгән: муниципаль мөлкәтне бүлешү максатларында башка муниципаль берәмлек милкенә тапшыру (кабул итеп алу) инициативасын белдерү хокукына үз милкендә мөлкәт булган муниципаль берәмлекнең дә, мөлкәткә дәгъва белдерүче муниципаль берәмлекнең дә җирле үзидарә органнары ия була; муниципаль мөлкәтне тапшыру (кабул итеп алу) турындагы тәкъдим нигезләнгән булырга тиеш. Шул ук статьяның 2 һәм 3 өлешләре нигезләмәләре белән үз милкенә мөлкәт кабул итеп алуга дәгъва белдерүче муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы һәм мөлкәтне муниципаль берәмлек милкенә тапшыру

инициативасын белдергән муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы бер-берсенә җибәрергә тиеш булган документлар исемлекләре билгеләнгән. Бүленергә тиешле муниципаль мөлкәт исемлекләрен килештерү тәртибен гамәлгә ашыру кысаларында муниципаль мөлкәтне тапшыру (кабул итеп алу) турында тәкъдим җибәрелгән вәкаләтле җирле үзидарә органы алынган тәкъдимне ул кергән көннән алып бер ай эчендә карарга һәм муниципаль мөлкәтне тапшыру (кабул итеп алу) яисә аны тапшырудан (кабул итеп алудан) баш тарту турында карар кылырга тиеш (3 статьяның 1 һәм 3 өлешләре). Муниципаль берәмлекнең мөлкәт тапшыруны гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары һәм муниципаль берәмлекнең мөлкәт кабул итеп алуны гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары килештерелгән мөлкәт исемлекләрен раслыйлар һәм аларны башкарма хакимият органына җибәрәләр (3 статьяның 4 өлеше).

Китерелгән закон нормалары үзләренең турыдан-туры эчтәлегеннән һәм максатчан билгеләнешеннән чыгып, муниципаль мөлкәтне тапшыру (кабул итеп алу) турындагы тәкъдимне карауны нигезсез сузуга юл куймау максатларында муниципаль мөлкәтне бүлешү процедурасында катнашучыларны, шулай ук мөлкәтне тапшыру процедурасына, шул исәптән тиешле документлар юллауга, тапшырыла торган мөлкәт исемлеген килештерүгә һәм билгеләнгән килештерү процедураларын үткәрү срокларын үтәүгә карата таләпләрне билгеләүгә юнәлдерелгән.

Мөлкәт исемлекләрен караганда каршылыклар килеп чыкса, Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы дәгъвалана торган 1 өлеше нигезендә тиешле муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары башкарма хакимият органына каршылыклар беркетмәсен, мөлкәтне бүлешү турындагы документларны һәм башка документларны тапшыралар.

Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге норманы дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлеше һәм 3 статьясындагы 1 өлеше нормалары белән үзара бәйләнештә карарга кирәк дип саный, чөнки муниципаль мөлкәтне бүлешкәндә

каршылыкларны җайга салу өчен башкарма хакимият органына мөрәҗәгать итү өлешендә әлеге статьяның нигезләмәләрен гамәлгә ашыру җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары тарафыннан тиешле килештерү процедураларын башкарганнан соң гына мөмкин. Шуңа бәйле рәвештә шуны билгеләп үтәргә кирәк: башкарма хакимият органының җирле үзидарә органнарын муниципаль мөлкәтне бүлешүгә инициатива белдерүгә мәҗбүр итү чараларын куллану вәкаләтләре юк. Мондый хокукый җайга салуны билгеләү 122-ФЗ номерлы Федераль законның 154 статьясындагы 11.1 өлешенең 12 һәм 15 абзацлары күрсәтмәләренә бәйле, алар тарафыннан муниципаль мөлкәтне бүлешү процедурасына карата, шул исәптән тиешле муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының килештерелгән тәкъдимнәре буенча муниципаль мөлкәтне бүлешү турында карар кабул итү буенча Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органы вәкаләтләренең конкрет күләме билгеләнгән.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлешенең, 3 статьясындагы һәм 5 статьясындагы 1 өлешенең дәгъва белдерелә торган нигезләмәләре муниципаль берәмлекләр арасында муниципаль мөлкәтне бүлешүнең бердәм оештыру-процедура механизмының аерылгысыз өлешләре булып торалар, вәкаләтле җирле үзидарә органнарының эзлекле гамәлләрен регламентлаштыру зарурлыгына таяналар, башкарма хакимият органы компетенциясен тулысынча билгелиләр һәм шуның белән җирле һәм гомумдәүләт мәнфәгатьләре балансын тигез дәрәҗәдә саклыйлар.

Күрсәтелгән закон нигезләмәләре эчтәлегеннән чикләре үзгәртелгән очракта муниципаль берәмлекләр тарафыннан муниципаль мөлкәтне башка муниципаль берәмлек милкенә фактта тапшыруга (кабул итеп алуга) инициатива белдерү хокукы гамәлгә ашырыла ала торган конкрет срок ачыкланмый. Шул ук вакытта бу хәл карала торган хокукый җайга салу эчтәлегенең әлеге аспектта билгесезлеге турында раслый алмый, чөнки дәгъвалана торган нормалар үзләренең конституциячел-хокукый мәгънәсендә

җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары югарыда аталган эзлекле гамәлләрне тормышка ашыру юлы белән аларның тайпылышсыз үтәлүен тәэмин итәргә тиеш дигәнне аңлаталар һәм үзләреннән-үзе муниципаль берәмлекләр өчен муниципаль мөлкәтне бүлешкәндә аны тапшыру (кабул итеп алу) процедурасында катнашу тиешле муниципаль берәмлекләр өчен мәҗбүри дип билгеләгән 122-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләреннән килеп чыга торган тиешле бурычтан тайпылу мөмкинлеген тудырмыйлар. Мондый алым муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртүнең шундый үзгәртеп коруларны гамәлгә ашыру буенча муниципаль берәмлекләрнең инициативалы дискрециясенә һәм үзара ризалыгына нигезләнгән конституциячел табигатенә бәйле, бу үзеннән-үзе муниципаль мөлкәтне муниципаль берәмлекләр арасында бүлешү максатларында аны башка муниципаль берәмлек милкенә тапшыруга (кабул итеп алуга) инициатива белдергәндә тиешле срокларның үтәлүен күздә тота. Шул ук вакытта җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру намуслылык презумпциясенә һәм аларның закон өстенлеге, тигезлек һәм гаделлек, гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын саклау гомуми хокук принципларына бирелгәнлегенә нигезләнергә тиеш.

Башка сүзләр белән әйткәндә, чикләрне үзгәртү инициативасы нигезле дип табылса, социаль-икътисади факторлар аркасында барлыкка килгән һәм шуның кысаларында Россия Федерациясе субъекты законы кабул ителгән булса, Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясындагы икенче өлеше нигезендә тиешле муниципаль берәмлекләр арасында муниципаль мөлкәтне бүлешү процедурасын гамәлгә ашыру һәм андый мөлкәтне бүлешү турында карар кабул итү өлешендә федераль һәм республика законнары таләпләрен алга таба үтәү бурычы барлыкка килә. Югыйсә җирле үзидарәнең бер органы тарафыннан муниципаль мөлкәтне тапшыру (кабул итеп алу) турында тәкъдим җибәрелгәннән соң җирле үзидарәнең тиешле вәкаләтле органнары муниципаль мөлкәт бүлешүне юридик рәсмиләштерү процессын

үз вакытында башларга тиеш дип күзалланган булмаса, чикләрне үзгәртү процессы мәгънәсен югалткан булыр иде.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган нормалары әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча муниципаль мөлкәтне муниципаль берәмлекләр арасында бүлешкәндә аны тапшыруга (кабул итеп алуга) инициатива белдерүгә комачауламыйлар, Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртү процедурасының системалы элементлары булып торалар һәм, димәк, кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең хокукларын киметмиләр һәм башкача бозмыйлар һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенең 18 (беренче өлеш), 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 55 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына каршы килмиләр.

4. Дәгъва белдерелә торган нормаларны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану чикләрне үзгәртү бер муниципаль берәмлекнең аерым торак пунктлары территорияләрен икенче муниципаль берәмлек территориясенә кертүгә китерә торган очракта аларны үзгәртү тәртибен хокукый җайга салуны алга таба камилләштерүгә комачауламый. Татарстан Республикасы Конституция суды шуңа игътибар итә: хокук кулланучылар тарафыннан тиешле закон нигезләмәләрен төрлечә аңлатуны бетерү максатында республика законнарының карала торган өлкәсе өстәмә җайга салуны таләп итә. Муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртү механизмының аерылгысыз элементы буларак муниципаль мөлкәтне муниципаль берәмлекләр арасында бүлешүгә инициатива белдерү өчен соңгы срокларны һәр конкрет очракта билгеләү дәгъва белдерелә торган нормаларны барлык хокук кулланучылар тарафыннан бертөрле аңлауга һәм куллануга, шулай ук гражданнарның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруны һәм яклауны тәэмин итү буенча конституциячел әһәмиятле максатларга ирешүгә ярдәм итәр иде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67, 68, 69, 71, 73 статьяларына һәм 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Муниципаль милектәге мөлкәтне бүлешүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» 2008 елның 6 августындагы 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлеше, 3 статьясы һәм 5 статьясындагы 1 өлеше нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазифаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә әлеге Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 81-П**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**